

Резеда Вәлиева

# Яраттым шул, яраттым...

*Җырлар һәм романслар*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2010

УДК 821.512.145-1:784
ББК 84(2Рос=Тат)-5:85.314
В97

**Вәлиева, Р.Т.**

В97 Яраттым шул, яраттым... : җырлар һәм романслар / Резеда Вәлиева ; кереш сүз авт. Г.Садә. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 159 б.
ISBN 978-5-298-01929-3

Әлеге китапта Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Резеда Вәлиева сүзләренә язылган җырлар туплап бирелә.

УДК 821.512.145-1:784
ББК 84(2Рос=Тат)-5:85.314

ISBN 978-5-298-01929-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Вәлиева Р.Т., 2010

# *Таңнарны да җырлар уята...*

Татар балаларының инде ничәмә-ничә буыны күренекле шагыйрә Резеда Вәлиеваның йөрәк җылысы белән өртелгән, туган телебезне, туган илебезне зурлаган, әти-әниләребезне яратырга, намуслылыкка һәм әдәпкә өйрәткән самими шигырьләрен укып үсте. Моннан нәкь ярты гасыр элек ул үзенең нәни укучыларына «Минем дусларым» дигән беренче шигъри җыентыгын бүләк итте. Шул вакыттан алып шагыйрә кечкенә укучыларының иң якын, яраткан дустына әйләнде. Дистәләрчә китаплары белән ул балалар күңеленә яктылык, җылылык күпере сузды. Без аны хаклы рәвештә Балачак иленең вәкаләтле илчесе дип атый алабыз. Шагыйрә кайда гына булмасын, анда сөекле ана телебез, Тукай теле һәм, әлбәттә, татар шигыре тантана итә, татар җыры канат кага.

Татар җыры дигәннән, кадерле укучыларыбыз, сез кулыгызга алган менә бу затлы китапка, «Яраттым шул, яраттым...» дип аталган җыентыкка, Резеда ханымның «җыр күлмәге» кигән шигырьләре тупланган, ул җырларның ноталары да бирелгән. Яшь дусларыбызга гына түгел, өлкән буын кешеләре өчен дә кадерле бу китап. Ул җырлар вакыт сынавын узып, халык күңеленә кергән. Аларны кайда гына яратып башкармыйлар?! Иң куанычлысы, мөгаен, шулдыр: Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Резеда Тәфкәлүн кызы Вәлиева кулы белән язылган, күренекле композиторлар тарафыннан көйгә салынган бу җырлар озын гомерле. Аларның һәрберсе хакында аерым рәвештә, тәфсилләп сөйләргә мөмкин. Мәсәлән, «Яран гөл» (С.Чуганаев көе), «Казаным минем, Казаным» (Р.Бакиров көе), «Син – минем язларым» (Л.Батыр-Болгари көе), «Агыйдел агышлары» (И.Закиров көе) кебек җырлар тиз арада таралып, җыр сәнгатен сөючеләр тарафыннан яратып кабул ителде.

Адәм баласының иң кайнар, иң матур хисе – ул, әлбәттә, мәхәббәт тойгысы. Шагыйрә өчен бу тема аерата якын. Аның шушы җыентыкка «Яраттым шул, яраттым...» (О.Усманов көе) дип исем бирүе дә тикмәгә генә түгелдер. Чөнки бу җыр бер-берләрен янып сөйгән, мәхәббәт утында янган меңнәрчә кешеләрнең җанына һәм рухына тәңгәл килә.

Китапта шулай ук безнең өчен иң кадерле кешеләр булган әниләргә һәм әтиләргә багышланган җырлар аерым игътибарга лаек. Резеда Вәлиева бу өлкәдә иң уңышлы иҗат итүче авторларыбыздан санала. Аның «Әниемә» (Г.Максимов көе), «Әткәмне сагынганда» (И.Дәүләтшин көе), «Әниләр бәйрәме» (Р.Асиков көе), «Бәхилләшми, әнкәй, ник киттең?..» (А.Салихова көе), «Ялгыз ана» (Т.Бадыгин көе) дигән җырларын тыныч кына тыңлап булмый. Шагыйрәнең әлеге изге теманы күтәрүенә сөенмәү мөмкин түгел...

Шагыйрә үзенә илһамны туган ягыннан, аның бәләкәйдән үк суын эчеп үскән чишмәләреннән, күбәләкләр куып уйнап йөргән шау чәчәкле болыннарыннан, куе калын урманнарыннан ала. Резеда Вәлиева – мәгъруур Урал-тау кызы. Шуңа да аның җырлары шул тауларга хас горурлык хисе белән сугарылган. Әйтик, «Туган илкәй» (Т.Бадыгин көе), «Дүшәнбикәм – җан иркәм» (Р.Бакиров көе), «Газиз туган җир генә» (И.Байтирәк көе) җырлары шуны раслый. Бу җырларда шагыйрәнең генә түгел, йөрәгендә татар каны аккан һәрберебезнең дә горурлыгы чагыла.


Резеда Вәлиева шигырьләренә язылган бик күп җырлар татар вокал сәнгатенең алтын фондына керделәр. Алар бүген дә, иртәгә дә татар халкының тугры юлдашлары булырлар. Безне якты таңнарга, кояшлы көннәргә алып барырлар.

*ГОСМАН САДӘ, шагыйрь,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# Сүрелмәс җырым син

*Р.Еникеев* көе

**Andantino tempo di valse**



Юлыма чыгасың,
Кулларың сузасың:
«Оныттың, кадерлем», – дисең дә.
Онытылмый назларың,
Яшьлегем язлары
Исемдә,
Исемдә,
Исемдә.

Шелтәле карама,
Ят керде арага,
Сагынып яшим, дип, мин генә.
Катлаулы язмышым,
Иң татлы сагышым
Син генә,
Син генә,
Син генә.

Гомерләр үтсә дә,
Күзләрем җитсә дә,
Күзләрем яз иткән нурым син.
Сүнсәм дә сүрелмәс,
Үлсәм дә өзелмәс
Җырым син,
Җырым син,
Җырым син.

# *Яран гөл*

*С.Чуганаев* көе

**Andantino**



Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана
Бәгырькәем, мине күрдисә.

Кайгы-хәсрәтем дә юк сыман,
Йөрәк ярсый, яна ут сыман.
Газапланам иртә-кичләрен,
Әйталмыйча йөрәк хисләрен.

Яннарыма гына килсә иде,
«Сөям сине, бәгърем», – дисә иде,
Күзләреннән алмый күзләрем,
Әйтер идем йөрәк серләрем.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана
Бәгырькәем, мине күрдисә.

# *Казаным минем, Казаным*

*Р.Бакиров* көе

**Allegretto**



Туган җирем – Татарстан,
Үзем – Идел баласы!
Туган телем – татар теле,
Мәккәм – Казан каласы.

К у ш ы м т а:
Казаным, минем Казаным,
Туган калам, башкалам.
Үз телемдә җырлыйм синдә,
Үз телемдә шатланам.

Бабам синдә гомер кичкән.
Синдәдер тамырларым,
Синдә тәүге мәхәббәтем,
Җырланасы җырларым.

К у ш ы м т а.

Шанлы тарих – үткәннәрең,
Ак бәхетләр – көткәнең.
Туган телем, иркен көнем –
Безгә бүләк иткәнең.

К у ш ы м т а.

Ярым ай яна түреңдә,
Нурын сибеп тын гына.
Сөембикә манарасы
Көмеш нурда коена.

К у ш ы м т а.

# Китмә, сөю

*М.Шәмсетдинова* көе



Китмә, сөю, китмә күңелемнән,
Ялгызлыкка мине ташлама.
Күрәсеңме, язның назлавына
Пар тургайлар ничек шатлана?!

Китмә, сөю, китмә күңелемнән,
Күзләр хөкеменә күнмә син.
Күзләремә нурлар сирпеп янган
Зәңгәр йолдызларым сүнмәсен.


Үрелмәсен күңелем гөлләренә
Көзге кырауларның салкыны,
Язлар булсын һаман йөрәгемдә,
Сүрелмәсен яшьлек ялкыны.

# Рәхмәт, әнкәй, сиңа

*Т.Вәлиев* көе

**Tempo di valse**







Шомырт чәчәк атса,
Илгә кошлар кайтса,
Җаным тула минем назларга.
Рәхмәт, әнкәй, сиңа,
Якты тормыш миңа
Бүләк иткән өчен язларда.

Йөрәк җылың белән,
Бишек җырың белән
Күңел кылларымны чирткәнсең.
Рәхмәт, әнкәй, сиңа,
Сабый чакларымнан
Бу дөньяга гашыйк иткәнсең.

Язгы кояш төсле
Сулмас яшәү көчен
Биргәнсең син миңа гомергә.
Рәхмәт, әнкәй, сиңа,
Кояш булып миңа
Мәңге-мәңге яшә бу җирдә!

# Татарстан

*Р.Бакиров* көе



Туган ягым минем – Татарстан,
Сызылып кына ата анда таң.
Сызылып кына аткан таңнарыңны
Балачактан өзелеп яратам.

Туган ягым минем – Татарстан,
Талгын гына исә җилләрең.
Талгын гына искән җилләр кебек
Тыныч булсын килер көннәрең.

Туган ягым минем – Татарстан,
Нигезендә алтын чайкала.
Иңнәрендә – Идел, ә түрендә
Балкый Казан – гүзәл башкала.


Туган ягым минем – Татарстан,
Якты булсын барыр юлларың.
Тукайларың, Мусаларың кебек
Дан яуласын мәңге улларың.

# *Син – минем язларым*

*Л.Батыр-Болгари* көе

**Moderato con moto**






Сине миңа якты язлар бирде,
Ничә язлар инде без бергә.
Ничә еллар һаман сөям, янам,
Мин язларда калдым гомергә.

К у ш ы м т а:
Син – минем язларым,
Сүрелмәс назларым,
Кояшым күңелем күгендә.
Синең кочагыңда,
Онытылып назыңда,
Яратам, яратам, яратам бүген дә...

Чәчәк аткан бәхет бакчабызның
Җимешләре нурсыз сулмасын.
Сиңа баглыйм гомеремне, бәгърем,
Мизгеле дә синсез узмасын.


К у ш ы м т а.

Синең кайнар сөю учагында
Янар идем тагын, тагын да.
Син булганда күңлем мәңге сүнмәс,
Яшьлек дәрте сулмас җанымда.

К у ш ы м т а.

# Агыйдел агышлары

*И.Закиров* көе



Агыйдел агышлары,
Зифадыр камышлары.
Агыйделнең бер сылуы
Йөрәгем сагышлады.

К у ш ы м т а:
Агыйдел яры текә,
Сулары ерак китә,
Язны көткән назлы гөлдәй,
Күңелем аны көтә.

Агыйдел суы саллы.
Дулкыннары ак яллы.
Агыйделкәй буйларында
Аккоштай ярым калды.

К у ш ы м т а.

Агыйдел салмак ага,
Аккош канатын кага.
Аккош кебек назлы ярым
Күңел салмас башкага.

К у ш ы м т а.


Таңнар аткан чагында
Агыйдел якларында,
Яннарына барыр идем
Дулкын канатларында.

К у ш ы м т а.

# *Әткәем*

*Л.Батыр-Болгари* көе






Күңелем күгендә балкыйдыр бүген дә,
Балкыйдыр бүген дә бер исем,
Тормышка юл биргән, җаныма нур өргән
Иң якын, газиз лә бер кешем.

К у ш ы м т а:
Әткәем, әткәем, күңлемдә, җанымда
Мәңге син яшь булып калырсың.
Әткәем, кадерлем, күзләрең нурында
Яшермә йөрәгең сагышын.

Син минем әткәем, син минем терәгем,
Кояшым син тормыш юлымда.
Сөюем, хөрмәтем, йөрәгем рәхмәте
Чагылсын сиңа бу җырымда.


К у ш ы м т а.

Күп еллар үтсә дә, узса да гомерләр,
Сүрелсә дә нурлы йөзләрең,
Сөюнең олысын, мәхәббәт җылысын
Гел синнән, синнән мин эзләрмен.

К у ш ы м т а.

# *Уйнама, гармун*

*Т.Бадыгин* көе



Авыл өстенә авыр моң ята:
Кемдер өздереп гармун уйната.
Гармуны аның үксеп елыйдыр,
Авыл, тын калып, аны тыңлыйдыр.

К у ш ы м т а:
Кем йөри шулай гармунын тартып,
Ялгыз йортларда сагыш уятып.
Әй, гармун, гармун, уйнама, тукта,
Моңлы җаннарны елатма юкка.

К у ш ы м т а.

Туган авылның тын урамнары
Оныткан инде гармун моңнарын.
Онытсын инде, сызланма юкка,
Сулган йөрәкне уятма, тукта.

К у ш ы м т а.

Уятма юкка, сүнсен өметләр,
Кайтмаска киткән моннан егетләр...
Уйнама, гармун, җитте, кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

# Газиз туган җир генә

*И.Байтирәк* көе

**Moderato**



Сандугачкай, сайра, сайра,
Котлап язгы таңнарны.
Туган җирдәй гүзәл җырлар
Дөньяда тагын бармы?

Сайра, сайра, сандугачкай,
Кунып сөйгән талыңа.
Туган якның тын җилләре
Тылсым өрсен җаныңа.

Күрче, дөнья нинди матур,
Тирә-ягы гөл генә.
Гөлбакчадай ямьле була
Бары туган җир генә.

Сайра, сайра, сандугачкай,
Сайрар моңың бер генә:
Чит җирләрдән сагынып кайткан
Газиз туган җир генә.

# Жырламагыз әле, әй, шул жырны

*Р.Бакиров* көе

**Moderato**



Җырламагыз әле, әй, шул җырны,
Өзелә лә, өзелә үзәгем.
Мөлдерәмә инде күңелләрем,
Авырлыклар белән түзәмен.
Җырламагыз әле, әй, шул җырны,
Телем-телем теленә бәгырем.
Аерылмыйча нигә белмибез соң
Бергәлеккәйләрнең кадерен...

Җырламагыз әле, әй, шул җырны,
Онытылсын ул, калсын еракта.
Төзәтеп лә булмас хаталар бар,
Үкенеп тә инде, елап та...
Җырламагыз әле, әй, шул җырны,
Җуйдырмагыз еллар арасын.
Кузгатмагыз, зинһар, йөрәгемнең
Мәңге төзәлмәслек ярасын.

# *Кермә, бәгърем, кермә төшләремә*

*Р.Бакиров* көе

**Agitato. Amoroso**



Кара күлмәк киеп өсләреңә,
Кермә, бәгърем, кермә төшләремә,
Күңелемә авыр итәсең.
Үпкәләгән төсле, тып-тын гына,
Күзләремә карап моңсу гына,
Борыласың, тагын китәсең...


Үткәннәрне кабат-кабат күзлим,
Аерылышуның сәбәпләрен эзлим,
Гаепләрем минем кайда соң?
Тик аңламыйм, аны табулардан,
Үткән гаепләрне танулардан
Бүгенгегә нинди файда соң?

Кермә, бәгърем, кермә төшләремә,
Төшмә инде, төшмә исләремә,
Безнең язлар калды еракта.
Үткән язлар мәңге кире кайтмас,
Сулган гөлләр кабат чәчәк атмас,
Үкенеп тә инде, елап та.

# *Сүнмәс ут яна*

*Г.Максимов* көе

**Andante**



Илем өстендә ап-пак болытлар
Аккошлар кебек талгын агалар.
Илем күгендә якты йолдызлар
Җем-җем җемелдәп, уйнап яналар.

Киң кырларында туган илемнең,
Алтындай тулып, башаклар пешә.
Туплардан калган яраларына
Энҗе-көмештәй тамчылар төшә.

Йортлар артыннан калкадыр йортлар:
Халкым өр-яңа шәһәрләр кора.
Һәр шәһәрнең күкрәк-түрендә
Сакчылар төсле һәйкәлләр тора.


Һәйкәлләр тора: мәңге хәтердә
Авыр елларның кайгы-сагышы.
Һәйкәлләр тора кисәтеп җирдә
Вакыйгаларның хәтәр агышын.

Каһарманнарның йөрәге төсле,
Горур талпынып сүнмәс ут яна...
Онытма моны, туктап янында,
Ихтирам белән башың и аңа!

# *Пар алмагач*

*Р.Бакиров* көе

**Allegretto**



Пар алмагачлар утырттык
Парлашкан көзебездә,
Бәхетебезнең бер көзгесе
Булыр дип үзебезгә.

К у ш ы м т а:
Пар алмагач чәчәк ата
Ямьле язлар иркендә.
Пар алмагачлар бәхете
Килсә икән һәркемгә.

Кем уйлаган бәхетебез
Шулай тиз сулыр диеп,
Алмагач гомереннән дә
Кыскарак булыр диеп.


К у ш ы м т а.

Инде һәр яз алмагачлар
Гөрләп чәчәк аталар.
Йөрәгемнең әрнеп янган
Ярасын яңарталар.

К у ш ы м т а.

# Кырларыңа мәхәббәтем җырлап киләм

*Т.Вәлиев* көе



Туган җирем, чыксам иркен кырларыңа,
Хәйран калам тургайларың моңнарына.
Гашыйк булып зәңгәр күзле гөлләреңә,
Йөзем куям талгын-йомшак җилләреңә.


Аяк астым – хәтфә кебек яшел чирәм,
Һаваларың татлы синең, хуш ис кенә.
Бәхетемнән сайрар коштай канатланып,
Кырларыңа мәхәббәтем җырлап килэм.

Җырлап килэм мәхәббәтем-җырларымны,
Күңелемә сарган шатлык-моңнарымны.
Бүләк булсын сиңа сулмас йөрәк җырым,
Әй сөекле, әй шәфкатьле халкым минем!

# *Сипкелле кыз*

*О.Усманов* көе

**Allegro**



Таныштым бер кыз белән,
Яратуымнан үләм.
Шулкадәр яратуымны
Сипкелләреннән күрәм.

К у ш ы м т а:
Ялкын чәчен тарыймын,
Күзләренә карыймын.
Битләреннән үбә-үбә,
Сипкелләрен саныймын.

Йолдыз-йолдыз сипкелләр
Сибелгән йөзләренә.
Толым-толым чәчләре
Төшкәндер тезләренә.

К у ш ы м т а.

Чәчләрен кызыл, диләр.
Әллә шуңа бик чибәр.
Кызыл түгел, алтындыр,
Янып торган ялкындыр.

К у ш ы м т а.


Сипкелләре күптөрле,
Балкый йолдыз шикелле.
Чибәрлеге чиктән ашкан,
Өстәвенә – сөйкемле!

К у ш ы м т а.

# *Яраттым шул, яраттым…*

*О.Усманов* көе

**Moderato**



Алларыма ник чыктың,
Кулларымнан ник тоттың,
Күзләремә серле карап,
Дөньяларың оныттың?
Парлы биюгә дәштең,
Якын итеп эндәштең.
Эндәшмәдең, әйтерсең лә
Җаным белән серләштең.


К у ш ы м т а:
Күзләреңә караттың,
Зиһеннәрем тараттың.
Аһ ул күзләр, серле күзләр,
Яраттым шул, яраттым...

Матур иде күзләрең,
Елмайдым шул, түзмәдем.
Аерылгач та, юксынгандай,
Шул күзләрне эзләдем.
Чакырдың, мин килмәдем,
Яраттым дип белмәдем.
Шаян егет, нигә инде
Күңелем сихерләдең?

К у ш ы м т а.

# Умырзая чәчәк аткан чакта

*И.Дәүләтшин* көе



Умырзая чәчәк аткан чакта,
Ялгыз йөрим урман буенда.
Күңелләрем ләкин ялгыз түгел,
Син буласың һаман уемда.

Умырзая үскән уйсулыкта
Җем-җем иткән әллә кар микән?
Көтәр идем яңа карларны да,
Күрешер көннәр алда бар микән?

Күзләреңнең моңсу карашларын
Охшатам, дип, умырзаяга,
Күңелемә утлар салдыңмыни
Үтсен диеп гомере заяга?!

Умырзая чәчәк аткан чакта,
Ялгыз йөрим урман буенда.
Күңелләрем ләкин ялгыз түгел,
Син буласың һаман уемда.

# Кошлар кайткан чак иде…

*Г.Максимов* көе



Кошлар кайткан чак иде,
Сулар аккан чак иде.
Яшьлегебез яздай гөрләп
Чәчәк аткан чак иде.

К у ш ы м т а:
Каршыма килгән идең,
Елмаеп көлгән идең.
«Инде таптым, гомеремдә дә
Югалтмам», – дигән идең.

Күңелдә вәгъдә сүзең,
Юлларда һаман күзем.
Язын кайткан кошлар кебек
Кайтырсың микән үзең?


К у ш ы м т а.

Су өсләре ак күбек,
Мамык тараткан кебек.
Берәүне дә яраталмам
Сине яраткан кебек.

К у ш ы м т а:
Каршыма килсәң иде,
Елмаеп көлсәң иде.
«Инде таптым, гомеремдә дә
Югалтмам», – дисәң иде.

# Зәңгәр чәчәк

*Т.Вәлиев* көе



Зәңгәр чәчәк, күзләреңдә
Энҗеме соң, яшьме соң?
Ник карыйсың мөлдерәтеп,
Ник бер сүз дә дәшмисең?


Зәңгәр чәчәк, моңсуланып
Карама миңа һаман.
Мин үзем дә, синең кебек,
Сагыну утында янам.

Зәңгәр чәчәк, хәлләреңне
Әйтмәсәң дә беләм бит.
Авыр икән аерылулар,
Сагынулардан үләм бит.

Зәңгәр чәчәк, хәлсезләнеп
Сарылма арышларга,
Кавышулар килер бер көн,
Бирешмик сагышларга...

# Әткәмне сагынганда

*И.Дәүләтшин* көе



Әткәй, бәгърем, тагын сиңа килдем,
Сөйгән гөлләреңне китердем.
Син бит, әткәй, мине, артык сөеп,
Шул гөлләрдәй назлап үстердең.

Юлларымда җил-давыллар купса,
Үз күкрәгең куеп сакладың.
Мин, тормышта язлар гына тоеп,
Синең ышыгыңнан атладым.

Гомеремдә бер очратсам әгәр
Синдәй яратканны баласын,
Әйтер идем: «Артык иркәләмә,
Уйла аның синсез каласын,
Кайгыларның әле буласын,
Уйла аның синсез каласын...»

# *Ак күлмәк кия иде*

*И.Закиров* көе



Ак күлмәк кия иде,
Елмаеп килә иде:
«Йөрәгемнең дәвалары
Син генә», – дия иде.
Килгәнен сизә идем,
Чыкмыйча түзә идем,
Яратсам да, юри үртәп,
Үзәген өзә идем.

Гармунының телләре,
Бер уйнап үтүләре.
Йөрәгемә утлар салды
Килмәскә китүләре.
Күзләрем алмый көтәм,
Үпкәләвең шул микән?
Тик бер генә килче, иркәм,
Үртәмәс идем бүтән.

# Үпкәлисез миңа, якташларым

*Г.Максимов* көе



Үпкәлисез миңа, якташларым,
Кайтмыйсың, дип, туган якларга,
Мәхәббәтең бер дә юкмыни, дип,
Бергә үткәргән сабый чакларга?

Туган ягым минем, туганнарым,
Мин сагынып сезне җан атам,
Урал тавын, ямьле Әй буйларын
Әүвәлгечә өзелеп яратам.

Искә төшкән саен күк Уралым,
Хыялларым дөрләп кабына.
Алтын дәрья кебек кырларының
Нурларыннан күзем чагыла.

Урал буйларында үстем яшьли,
Урал буйларында җыр тынмый,
Яшьли откан моңлы җырлар кебек,
Туган җирләр мәңге онтылмый...

# Их, авылым таңнары

*О.Усманов* көе

**Moderato**



Кайттым туган якларыма
Җырчы кошлар кайтканда,
Кошлар моңына күмелеп,
Таңнар сызылып атканда.

К у ш ы м т а:
Их, авылым таңнары,
Сызылып атулары,
Сандугачның чут-чут итеп
Сайрап уятулары.

Әрәмәлек эчләреннән
Челтер чишмә үтәдер.
Челтер чишмә буйларында
Иркәм мине көтәдер.


К у ш ы м т а.

Аны да шул таң кошлары
Сайрап уятты микән?
Сайрар кошлардай талпынып
Каршыма чыккан иркәм!

К у ш ы м т а.

# Үрмә гөл

*С.Чуганаев* көе



Үрмә гөлләр бөредә,
Язлар ямьгә төренә.
Мәхәббәтең үрмә гөлдәй
Йөрәгемә үрелә.

К у ш ы м т а:
Үрмә гөлләр үрләсен,
Җил сындыра күрмәсен.
Үрмә гөлдәй сылу иркәм,
Күзләр генә тимәсен.

Үрмә гөлләр ак икән,
Чәчәкләре вак икән.
Өзгәләнә үзәккәем –
Сөюләрең хак микән?

К у ш ы м т а.

Үрмә гөлләр сибәрсең,
Күзләр җиткәч өзәрсең.
Сөйгән ярың ятны сөйсә,
Ни хәл итеп түзәрсең.

К у ш ы м т а.

Үрмә гөлләр ал гына,
Яфраклары тар гына.
Җаным сөйгән ярым ла син,
Янып сөйгән яр гынам.

К у ш ы м т а.

# *Кайтыр идем*

*М.Морзаханов* көе



Хәтеремдә туган якларыма
Сагынышып кошлар кайтканы.
Көмеш тәңкә сибеп суларга,
Таңнар сызылып атканы.

Туган якларымның моңнары –
Челтер чишмәләрнең җырлары,
Аланнарда чәчәк чыңнары
Күңелемдә мәңге тынмады.

Кайтыр идем туган якларга,
Сандугачлар моңын ятларга,
Чабып кына акбүз атларда
Шунда калган бала чакларга.

Урал буйларында үстем яшьли,
Урал буйларында җыр тынмый.
Яшьли откан моңлы җырлар кебек,
Туган җирләр мәңге онтылмый.

# Уйна, гармуным, йөрәгем моңын

*О.Усманов* көе



Җәйге кичләрдә ялгызым калдым,
Сагыш-моңнарым тик сиңа салдым.
Ела син үксеп, ела, гармуным,
Ул аңлар, бәлкем, йөрәгем моңын.

К у ш ы м т а:
Сыза ла йөрәк,
Өзелә үзәк.
Сөйлә, гармуным,
Йөрәгем моңын.
Ул ишетмәсме,
Килеп китмәсме,
Соңгы ялгышым
Гафу итмәсме?

Уйна, гармуным, йөрәгем моңын,
Сагынуларымны әйт аңа тизрәк.
Әйт аңа тизрәк, өзелә үзәк,
Соңгы ялгышым төзәтче, төзәт.

К у ш ы м т а.

Аңласа иде ачы сагышым,
Кичерсә иде соңгы ялгышым.
Соңгы ялгышым – авыр язмышым,
Әйтче, гармуным, ул аңлармы соң?..

К у ш ы м т а.

# Сылу яр

*О.Усманов* көе

**Moderato**



Су буенда бер сукмак бар,
Үзе озын, үзе тар.
Сөймәс булгач, су юлына
Нигә чыктың, сылу яр?
Нигә күрдем тагын да
Сулар алган чагында?
Шуннан бирле тынгы белмим,
Давыл купты җанымда.

К у ш ы м т а:
Әй, сылу яр, сылу яр,
Су буенда уен бар.
Уеннарга чыгар булсаң,
Аңлашырга уем бар.

Тальян гармун кулымда,
Күзләрем су юлында.
Шул юлларда очрадың да
Мәңге калдың уемда.
Очрарсыңмы тагын да
Сулар алган чагында?
Янарсыңмы, минем кебек,
Мәхәббәт учагында?

К у ш ы м т а.

# Әниләр бәйраме

*Р.Асиков* көе

**Con espressione**



Нигә бүген бөтен җирдә
Чәчәкләр балкый бездә,
Нигә кояш көлеп карый –
Беләбез һәммәбез дә.

Бүген – әниләр бәйрәме,
Бүген җирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.

Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Җирдә барлык балалар.

Мин дә котлыйм, әнкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә!

# *Сайра, тальян*

*И.Якупов* көе



Кичке эңгер төште суларга,
Күләгәләр ятты юлларга.
Без киләбез бергә,
Күгәрчендәй гөрләп,
Тын бакчада биеп-уйнарга.

Кушымта:
Сайра, тальян, туктама,
Иркәм чыксын әле уртага.
Каршыма килсен биеп,
Уйна син, туктама.

Юл буйлары гөлгә күмелгән,
Нур сибелә гүя күңелгә.
Тәүге татлы хисләр
Онытылмас һич тә,
Ялкыннары җитәр гомергә.


Кушымта.

Тын бакчада тальян чыңнары,
Үзәкләргә үтә моңнары.
Ак күлмәкләр киеп,
Кызлар йөри биеп,
Аккошлардай горур сыннары.

Кушымта.

# *Яратам бит*

*И.Дәүләтшин* көе



Яратам, дип, яратам, дип, яратам,
Күңел кылларын чирттең.
Яратам бит, яратам бит, яратам,
Ник эндәшмичә үттең?

К у ш ы м т а:
Чакырдың бит, чакырдың,
Килдем, каршы алмадың.
Сагындым бит, сагындым,
Нигә күз дә салмадың?

Инде килмәм, сагынам, димәм,
Чакырма син, көтмә син.
...Йөрәк, йөрәк, тын син тизрәк,
Әрнүең ишетмәсен...

К у ш ы м т а.

# Аккош зары

*Т.Бадыгин* көе



Күл буйлары нигә боек бүген?
Төнбоеклар нигә башын игән?
Тынып калган сылу камышлар да,
Зәңгәр күлгә нинди кайгы килгән?

К у ш ы м т а:
Күл буенда ялгыз аккош
Өзгәләнеп парын эзли.
Зәңгәр күккә томырылып
Аваз сала, җаны түзми.
Моң-зары аның
Кемнең бәгърен өзми...

Кайларда син, кайда, гүзәл парым,
Өзелеп кенә сөйгән назлы ярым?
Газиз җаның кыйды кемнәр генә?
Күңелемдә кара төннәр генә...

К у ш ы м т а.

Күксел нурга чумган күл буенда
Кайчан гына әле бәйрәм иде.
Йөрәкләрне телгән авыр сагыш
Кайчан гына, кайдан гына килде?

# Гөлнаракай, Гөлнара

*И.Арсланов* көе

**Allegretto**



Язгы сабантуйларында
Күрдем сине, Гөлнара,
Буй-сыннарың әле дә булса
Күз алларымда тора.

К у ш ы м т а:
Гөлнаракай, Гөлнара,
Бик сагынсаң, хәлләремне
Моңлы тургайдан сора,
Гөлнаракай, Гөлнара.

Кара күзләрең балкытып,
Елмайсаң уйчан гына,
Йөзләреңә ялкын булып
Сөйкемле нур кабына.

К у ш ы м т а:
Гөлнаракай, Гөлнара,
Бик сагынсаң, хәлләремне
Искән җилләрдән сора,
Гөлнаракай, Гөлнара.

Таңнар ата, Чулпан калка,
Сандугачлар уяна.
Язгы таңдай бер килер дип,
Күңелләрем юана.

К у ш ы м т а:
Гөлнаракай, Гөлнара,
Бик сагынсаң, хәлләремне
Сандугачлардан сора,
Гөлнаракай, Гөлнара.

# Әнием

*Г.Максимов* көе

**Con espressione**



Сабый чагым, алсу таңым
Зәңгәр болыт артында.
Сабый чактан бер моң килә
Хыялым канатында.

К у ш ы м т а:
Әнием, әнием,
Онытмам гомеремдә.
Йөрәгеңнең җылысын
Сакларммын күңелемдә.

Яшисең син шул хыялда
Ләззәтле бер наз булып.
Исемең тибрәнә күңелдә
Тылсымлы аваз булып.

К у ш ы м т а.


Ачыксам да, талчыксам да
Йөгереп килә идем.
Наз сораган бәбкә кебек,
Куеныңа керә идем.

К у ш ы м т а.

# Ник югалды болай эзләрең?

*Г.Әхмәтҗанова* көе

**Tempo di valse**



Кайтам, диеп киткән идең,
Бәхет вәгъдә иткән идең,
Оныттыңмы биргән сүзләрең?
        Кар-бураннар куды микән,
        Язгы сулар юды микән,
        Ник югалды болай эзләрең?

Йөрәгемнән ничек куыйм?
Җаннарымнан ничек җуйыйм?
Күңелем һаман сине көтә бит.
        Вәгъдәсез яр нигә кирәк,
        Оныт аны, оныт, йөрәк,
        Яшь гомерем зая үтә бит.

Кошлар кайта, кошлар китә,
Гомеркәйләр һаман үтә,
Аккан сулар кебек тын гына.
        Язлар бәхет алып килми,
        Якты таңнар шатлык бирми,
        Күңелемдә сагыш-моң гына...

# *Оч син, жырым!*

*Г.Максимов* көе



Оч син, җырым, оч син еракларга,
Җилләр сине күтәп алсыннар.
Сандугачлар, сайрар сандугачлар,
Моңнарыңа хәйран калсыннар.

Оч син, җырым, алтын диңгез кебек
Иген кырларында чыңла син.
Моң яраткан халкым, сөенә-сөенә,
Онытылып сине тыңласын.

Оч син уйнап, шаян тургайлардай
Зәңгәр киңлекләргә омтыл син.
Син чыңлаган җирдә шатлык тусын,
Күңелләрдә кайгы онтылсын.

# Казански кун итек

*Ф.Вафин* көе



Сабантуй ярминкәсеннән
Алып кайттым күн итек.
Гади итек түгел ләкин –
Казански күн итек!

К у ш ы м т а:
Әй күн итек, күн итек,
Торам исләрем китеп.
Биюче итте үземне
Казански күн итек!

Шул итекләрне киюгә
Белмим ни генә була,
Аякларым, кыбырсынып,
Биергә генә тора.

К у ш ы м т а.

Тальян да уйнап җибәрсә
Бию көйләрен генә,
Минем итекләрне инде
Тыеп торырмын димә.

К у ш ы м т а.

Җилдереп алып китә,
Очыртып кына йөртә,
Шундый да оста баса,
Вәт бит, малай, тамаша!

К у ш ы м т а.

Биетә генә итекләр,
Очыртып та сикертеп.
Шуннан бирле биеп йөрим,
Сәхнәләрне бер итеп.

К у ш ы м т а.

Гөрләтеп кул чаба халык,
Тик үзем белмим менә:
Әллә миңа чаба алар,
Әллә күн итегемә...

К у ш ы м т а.

# *Кайт син, балам...*

*Ф.Мортазин* көе

**Andante**



Язгы сулар ургып аккан чакта,
Күңелләрем сине юксына.
Язлар ямьле түгел синнән башка,
Кайт син, балам, тизрәк кайтсана.
　　Кайт, күз нурым, кайт туган ягыңа,
　　Тугайларың сине сагына.

Өй түрендә кошлар оя корды,
Сайрауларын тыңлап юанам.
Алар тиздән бала үстерерләр,
Минем генә йортым тын һаман.
　　Кайт син, балам, кайт туган ягыңа,
　　Тургайлар да сине сагына.

Яз кайтмады, бәлки, көз кайтыр, дип,
Сине көтеп яшим мин һаман.
Узмасын ла гомерем сагыш белән,
Кайт, күз нурым, тизрәк кайт, балам,
　　Кайт син, балам, кайт туган ягыңа,
　　Газиз әнкәң сине сагына.

# *Ник утми сагышларым?*

*А.Салихова* көе

**Tempo di valse**



Яр буйларын ялгыз буйлыйм
Суларга карап кына.
Сагынуым басылса иде
Кош булып сайрап кына.

Кушымта:
Суларның агышлары,
Тибрәлә камышлары.
Сулар китә, еллар үтә,
Ник үтми сагышларым?

Сулар ага ургылып,
Язгы ярларга тулып.
Яр буенда басып калдым
Ялгыз аккоштай булып.

Кушымта.

Сулар да китә инде,
Язлар да җитә инде.
Язгы гөлдәй яшь гомерем
Ялгызым үтә инде.


Кушымта.

Киттең ерак якларга,
Якын булдың ятларга.
Сагышларың калдырдыңмы
Ядкарь итеп сакларга?

Кушымта.

# *Туган телем*

*Р.Асиков* көе



Сандугачым, былбыл-гөлем,
Нигә моңлы синең телең?
Нигә болай сайрауларың
Үзәгемне өзә минем?


Тавышыңда туган якның
Чишмәләре чыңлап китә,
Иң якын көй-моңнарымның
Аһәңнәре чагылып үтә.

Моңнарыңның тәмен беләм,
Бигрәк инде якын күрәм.
Тугандаштыр синең телең
Минем туган телем белән!

Туган телем – татар теле,
Сандугачлар теле бит ул!
Үзе матур, үзе бөек,
Аһәңле һәм моңлы бит ул.

# *Далада*

*Р.Асиков* көе



Тып-тын дала. Монда сугыш үткән.
Көрәш барган монда, кан аккан.
Тәмуг кебек ялкын дөрләп яткан,
Утлы телен сузып һәрьяктан.

Көн тумаган. Ялкын-ут эчендә
Җир белән күк гүя тоташкан.
Җирләр тетрәп, күкләр күкрәп торган
Туплар улавыннан тоташтан.

Бүген тып-тын. Бөтен тирә-якта
Тибрәнә тик соры кылганнар.
Күпме ирләр монда, тынлык саклап,
Гомерлеккә тынып калганнар.

Ята алар, дәһшәт-ут яуса да,
Янаса да нинди куркыныч.
Сыкранмый да алар, уфтанмый да,
Илкәй генә булсын тик тыныч...

# *Бәхилләшми, әнкәй, ник киттең?..*

*А.Салихова* көе

**Moderato**



Еракларга киттем, сине үксез иттем,
Ничә еллар ялгыз интектең.
Шулкадәрле көткәч, улың кайтып җиткәч,
Бәхилләшми, әнкәй, ник киттең?..

Кушымта:
Кулларымда минем сагышлардан синең
Күз яшьләрең тамган хатларың.
Үкенечләр тулы синең соңгы юлың
Ниләр белән генә аклармын?..

Тирә-якны күзлим, төсләреңне эзлим,
Тик юк инде алар, югалган.
Йөргән эзләреңдә, язган сүзләреңдә
Җан әрнеткеч сагыш-моң калган.

Кушымта.

Юанычлар булып, сагынулар тулы
Хатларым ник сирәк килде икән?
Салкын кышларыңда, озын кичләреңдә
Хәлләреңне кемнәр белде икән?..

Кушымта.

Кәккүк тавышында ишетелә сыман
«Кайтчы» дигән моңсу сүзләрең.
Ничә еллар көткәч, кайтыр көнем җиткәч,
Ник аз гына, әнкәй, түзмәдең?..

Кушымта.

# Зәңгәр күзем

*Р.Бакиров* көе



Зәңгәр күзем, алсу йөзең
Нигә читкә борасың?
Каш астыннан серле карап
Ят кешедәй торасың.
Бер өздереп карадың да
Зәңгәр күзләрең белән,
Сихерләдең күңелемне,
Сагышларымнан үләм!

К у ш ы м т а:
Әйтер сүзем әйтә алмыйм,
Нишләттең, зәңгәр күзем?
Йөрәгемдә утлар яна,
Ни хәлләр итеп түзим?

Зәңгәр күзем, әйтер сүзем
Үзең дә сизәсең бит.
Юри җаннарымны үртәп
Үзәгем өзәсең бит.
Зәңгәр күзем, алсу йөзем,
Кайларда син, кая син?
Йөрәккәем яралы бит,
Кайдан табыйм дәвасын?

К у ш ы м т а.

# *Сары төнбоек*

*Р.Бакиров* көе



Күл ярлары түгәрәк,
Гөлләр үскән тирәләп.
Күл буйларын җәйләү итеп
Йөргән идек бергәләп.

К у ш ы м т а:
Сары төнбоек өзәм,
Бәйләмнәр итеп тезәм.
Төнбоек кебек, төнбоек кебек
Саргаймый ничек түзәм?

Күл басмасы тар микән?
Такталары пар микән?
Әйтегезче, төнбоеклар,
Күрешер көннәр бар микән?

К у ш ы м т а.

Пар аккошлар суларга
Төшкән чумып уйнарга.
Бәхетләреннән көнләшеп
Карап тордым шуларга.

К у ш ы м т а.

# *Кадерләрем булмады*

*О.Усманов* көе



Чәчләреңне толым-толым
Үреп төшерсәң иде.
Җаның сөйгән ярың белән
Гомер кичерсәң иде.

К у ш ы м т а:
Барган юлларым уңмады,
Чиләкләрем тулмады,
Әллә артык яратканга,
Кадерләрем булмады.

Чәчләреңне тарарсың, дип,
Тараклар бүләк иттең.
Чәчәк кебек чакларымда
Кызганмый ташлап киттең.

К у ш ы м т а.

Өздең лә үзәкләремне,
Агарттың чәчләремне,
Ниләр белән кайтарырсың
Түккән күз яшьләремне?


К у ш ы м т а.

Кара бөдрә чәчләремне
Таратып куялмадым,
Мин бит сине сөеп түгел,
Күреп тә туялмадым.

К у ш ы м т а.

# «Яратам» диюләрең...

*О.Усманов* көе



Атлыгып килүләрең,
Бер балкып көлүләрең.
Күңелемә яз китерде
«Яратам» диюләрең.

К у ш ы м т а:
Кил, бәгърем, кил генә,
Елмай гына, көл генә,
Шул сихерле сүзләреңне
Әйтче тагын бер генә.

Сызылып кына таң ата,
Сирень хуш ис тарата.
Сандугачлар сайрый сыман:
«Ярата, – дип, – ярата!»

К у ш ы м т а:
Әйтче тагын бер генә,
Яз килсен күңелемә.
Мин дә бит соң, бәгырькәем,
Яратам сине генә.

Әйтче тагын бер генә,
Ямь тулсын күңелемә.
Шул сүзләрнең кайнарлыгы
Җитсен бар гомеремә!

К у ш ы м т а:
Кил, бәгърем, кил генә,
Елмай гына, көл генә.
Шул сихерле сүзләреңне
Әйтче тагын бер генә.

# Яр буйлары – куш тирәк

*О.Усманов* көе



Яр буйлары – куш тирәк,
Шунда ашкына йөрәк.
Куш тирәкле туган җирем,
Синдәй гүзәлләр сирәк!
Яр буйлары – яшь чирәм,
Әйтерсең хәтфә келәм.
Хәтфә келәмнәрдән атлап,
Көн дә янына киләм.

К у ш ы м т а:
Яр буйлары – куш тирәк,
Шунда ашкына йөрәк.
Куш тирәкле туган җирем,
Бәхет өчен ни кирәк?!

Яр астында су ага,
Суы коя буага.
Яр буенда куш тирәгем,
Серем сөйлим мин аңа.
Яр буйлары тын гына,
Күңелем тулы моң гына.
Моңнар тулы күңелемне
Аңлый кебек ул гына.

К у ш ы м т а.

# *Сандугачлар серледер*

*О.Усманов* көе



Ак алъяпкыч ябармын дип,
Ак чиләкләр эшләттем.
Бер көн күрми түзә алмыйм,
Бәгърем, мине нишләттең?
Ап-пак күлмәкләр киясең,
Төшләремә керәсең.
Моңсуланып киләсең дә:
«Сагынам сине», – диясең.

Кушымта:
Сандугачлар серледер,
Серен ятлар белмидер.
Кеше телләренә кереп,
Хур буласым килмидер.

Юк, кирәкми, килмә син,
Сагынамын, димә син.
Ерак яшер серләреңне,
Ятлар сизә күрмәсен.

Кушымта.

# Күрешер таңнар атмады

*Р.Асиков* көе



Ак мамыклар оча микән,
Аккошлар кагынганда?
Җаннарымны кая куйыйм,
Назларын сагынганда?
Күл буйлары ямьле булмый,
Аккошлар тезелмәсә.
Моң булып түгелмәс идем,
Үзәгем өзелмәсә.

Күл өсләре тын гына,
Күңелем тулы моң гына.
Моңнар тулы күңелемне
Аңлый иде ул гына.
Пар канатлар какмады,
Күлгә аккош кайтмады.
Әрнер инде йөрәккәем,
Күрешер таңнар атмады...

# Дүшәнбикәм – җан иркәм

*Р.Бакиров* көе



Кайттым туган авылыма
Җырчы кошлар кайтканда,
Кошлар моңына күмелеп
Таңнар сызылып атканда.
Кайттык бергә сабантуйга,
Тальян моңын сагынып.
Каршы алды Дүшәнбикәм,
Яшел шәлен ябынып.

К у ш ы м т а:
Дүшәнбикәм, Дүшәнбикәм,
Гүзәллеген күр генә.
Туган авылым – Дүшәнбикәм –
Дөньяларда бер генә.


Дүшәнбикәм чишмәләре
Көмеш кебек уйныйдыр.
Дүшәнбикәм гүзәллеген
Күзләр күреп туймыйдыр.
Күбәләкле болыннарың,
Диңгез кебек кырларың.
Бүләк булсын, Дүшәнбикәм,
Минем йөрәк җырларым.

К у ш ы м т а.

# *Сине күрсәм*

*Т.Бадыгин* көе






Сине күрсәм, яңа җырлар туа,
Сүнгән хисләр дөрләп кабына.
Күңлем, ахры, һаман сине сөя,
Җаным, ахры, һаман сагына.

К у ш ы м т а:
Сөюсез бит гомер – кояшсыз көн.
Сөюсез бит язлар яз түгел.
Язгы гөлләр нурдан туймагандай,
Сөюләрдән туймый бит күңел.

Кара шулай, кара күзләремә
Моңсу гына итеп, яратып.
Янсын әйдә йөрәк, янсын дөрләп,
Бер карашың өчен җан атып.


К у ш ы м т а.

Чык син шулай, чык син юлларыма,
Күзләремә кара тын гына.
Ерагая барган көзге кояш
Нурын сипкән төсле моң гына.

К у ш ы м т а.

# *Яңа ел килә!*

*Р.Бакиров* көе



Минутлар артлы минутлар үтә,
Нурланып-балкып Яңа ел җитә.
Безгә яңа җыр килә,
Матур көй ишетелә.
Яңа ел килә, дуслар, Яңа ел!

Дусларым, безгә колак салыгыз,
Теләкләрегез әйтеп калыгыз.
Якты кабына утлар,
Очып үтә минутлар.
Яңа ел җитә, дуслар, Яңа ел!

Яңа ел килә, Яңа ел килә,
Котлыйм, дусларым, Яңа ел белән!
Яңа җыр бүләк булсын,
Еракка яңгырап торсын.
Яңа ел килде, дуслар, Яңа ел!

# *Сине эзлим*

*Р.Бакиров* көе

**Allegretto. Affettuoso**



Кая барсам, сине эзлим,
Сине генә күзлим бит.
Нишләттең бу күңелемне,
Күрми бер көн түзмим бит?
Ә син һаман шаяртасың,
Ә син һаман көләсең.
Кара күзләрең балкытып:
«Мин дә сөям!» – диясең.

К у ш ы м т а:
Йөзләреңне бер туйганчы
Килә күреп каласым.
Күрдем исә, күрдем исә,
Килә үбеп аласым.

Төшләремә керәсең бит
Ялгыз аккошлар булып.
Йокыларымнан уянам
Сагышларыма тулып.
Төшемдә дә, өнемдә дә
Һаман сине юксынам.
Синсез язлар килмәс сыман,
Синсез сөю юк сыман.

К у ш ы м т а.

# Өзгәләмә үзәгемне

*Р.Асиков* көе



Исемеңне җырга салып
Җырлар идем моңланып,
Җырлый алмыйм, туктап калам,
Авыр уйларга талып.

К у ш ы м т а:
Өзгәләдең үзәгемне,
Парың булыр идем, дип.
Мәңге парым була алмадың,
Зарым гына булдың бит.

Җиһанда язгы тантана.
Кошлар таба парларын.
Пар кошларны күргән саен,
Арта йөрәк зарларым.

К у ш ы м т а:
Гомер үтә, күзләр җитә,
Яшьлек коя чәчәген.
Коелган чәчәкләр кебек
Мөлдери күз яшьләрем.

Күзләр җитә, кошлар китә
Туып үскән ягыннан.
Кошлар кебек син дә тизрәк
Китсәң иде җанымнан...

К у ш ы м т а:
Өзгәләмә үзәгемне,
Парың булыр идем, дип.
Мәңге парым була алмадың,
Зарым гына булдың бит.

# Юксыну

*Р.Бакиров* көе

**Andantino**



Исләремә алам,
Оныта алмыйм һаман
Зәңгәр шәлләр бүләк иткәнең.
Шәлләреңә төреп,
Күзләремнән үбеп,
«Иркә гөлем» диеп әйткәнең.

Назлы сүзләреңнең,
Якты йөзләреңнең
Кадерләрен генә белмәдем.
Өзелеп сөйгән чакта,
«Килче» дигән чакта,
Уйный-көлә киттем, килмәдем.


Үкенечләр тулы
Шаулы яшьлек елы
Кайтмый икән, кайтмый бер үткәч.
Зәңгәр нурым сүнде,
Җаныма моң инде,
Якты дөньялардан син киткәч.

Шәлләреңне алып,
Иңнәремә салып,
Көзгеләргә багам моң гына.
Зәңгәр шәлләреңә
Иркә гөлкәеңнең
Күз яшьләре тама тын гына.

# *Сагышлы җыр*

*Р.Бакиров* көе

**Andante cantabile**



Мөлдерәмә булып,
Сагышларга тулып,
Күңелләрем сине юксына.
Төшләремне юрап,
Бер Ходайдан сорап,
Көтәм сине, иркәм, кайтсана.

Киткән кошлар кайтты,
Шомырт чәчәк атты,
Хуш исләре ятты гөлләргә.
Тик мин генә һаман
Ялкыннарда янам,
Калдырдың соң мине кемнәргә?

Синең төсең итеп,
Синең төсле итеп
Сөеп карыйм язның гөлләрен.
Кайт туган илләргә,
Очырма җилләргә
Кабатланмас яшьлек көннәрен.

# *Күрдем кошлар киткәнен*

*Р.Бакиров* көе



Күрдем кошлар, кошлар киткәнен,
Сиздем күзләр, күзләр җиткәнен.
Сизми калдым, күрми калдым
Яшь гомеремнең үткәнен.

К у ш ы м т а:
Түр бакчама чәчкән гөлем
Ал чәчәк атса иде.
Ал чәчәктәй яшь гомерем
Әйләнеп кайтса иде.

Исле гөлләр, гөлләр үскән лә,
Иелә җилләр, җилләр искәндә.
Сагынамын яшьлегемне,
Син исемә төшкәндә.

К у ш ы м т а.

Күл өсләрен сарган ак томан,
Яшьлегемне сагынып юксынам.
Анда минем моңсу ярым
Зарыгып көтәдер сыман.

К у ш ы м т а.

# Туган илкәй

*Т.Бадыгин* көе

**Moderato**



Туган илкәй...
Ни аһәңле, назлы исем!
Сизәм анда болыннарның татлы исен,
Ишетәм анда каеннарның серле шавын,
Тау астында салкын чишмә чылтыравын.


Туган илкәй...
Кырларыңның алтын төсен
Ашкынамын тик бер генә күрер өчен.
Саклыйм аңа чын мәхәббәт, сөю хисен,
Алам аннан мәңге сулмас яшәү көчен.

Туган илкәй...
Бу исемдә язгы таңнар,
Бу исемдә җанга рәхәт татлы моң бар.
Бу исемдә бөтен гомерем, бәхетем минем.
Җырларымның саф чишмәсе – туган җирем.

# Ялгыз ана

*Т.Бадыгин* көе






Ана тора мәйдан уртасында,
Еракларга текәп күзләрен.
Талгын җилләр сөеп үтә аның
Сары сагыш сарган йөзләрен.

К у ш ы м т а:
Тын һавада торна тавышлары
Еракларга яңгырап ишетелә.
Илдән киткән кошлар авазыннан
Йөрәк өзгеч сагыш-моң килә.

Һәр ел саен моңсу шул кошларны
Ялгыз ана кала озатып.
Кошлар китә, ана йөрәгендә
Авыр яраларны кузгатып.

К у ш ы м т а.

Күпме уллар калды чит җирләрдә
Ирек яулап газиз халкына.
Мәйданнарда ана сагышыдай
Мәңге сүнмәс утлар талпына.

К у ш ы м т а.

# *Яңа ел киче*

*Т.Бадыгин* көе



Унике кат суга сәгать теле,
Бигрәк моңлы суга ул быел.
Кысылып куя йөрәк, дулкынланып,
Канат җәя җиргә Яңа ел!

К у ш ы м т а:
Яңа ел киче, Яңа ел киче,
Алып чык тизрәк яңа таңнарга.
Яңа таң булып мәхәббәт килсен
Ярата белән назлы җаннарга.

Яңа ел киче, Яңа ел киче,
Теләкләремне аңлатыйм ничек?
Яңа ел киче, итмә ялгызым,
Кабынсын таңда өмет йолдызым.

К у ш ы м т а.

Кабынсын таңда өмет йолдызым,
Туңмасын җаным ачы җилләрдән.
Ак бураннарга көмеш нур сирпеп,
Бәхетем кайтсын ерак җирләрдән.

К у ш ы м т а.

# Әйдә барыйк аулак өйгә

*Т.Бадыгин* көе



Әйдә барыйк аулак өйгә,
Күңелле бит бигрәк тә.
Уйныйк, җырлыйк, кызлар күрик,
Дәрт уянсын йөрәктә.

К у ш ы м т а:
Эх, аулак өйләре,
Яңгырый дәртле көйләре,
Челтер чишмә чыңнарыдай
Кызларның көлүләре.

Без җырлый да беләбез,
Без бии дә беләбез.
Такмак әйтеп, сүз уйнатып,
Кызларны көлдерәбез.

К у ш ы м т а:
Эх, аулак өйләре,
Ашкынып көтүләре,
Гармун тартып, каш уйнатып,
Бер җырлап үтүләре.

Шаярабыз да көләбез,
Бергәләп гөр киләбез.
Аулак өйне яратабыз
Менә шуңа күрә без.

К у ш ы м т а:
Эх, аулак өйләре,
Яңгырый дәртле көйләре,
Челтер чишмә чыңнарыдай
Кызларның көлүләре.

# Әй чабата, чабата

*Т.Бадыгин* көе



Ярминкәгә барган идем,
Алып кайттым чабата, шул.
Аннан үзем җыр чыгардым
Чабатага карата, шул.

К у ш ы м т а:
Чабатасы, чабатасы,
Әллә инде кожаный, шул.
Бигрәк җиңел, бигрәк җайлы,
Салмам, ахры, пожалуй, шул.

Итек киеп бииләр,
Читек киеп бииләр.
Чабатаны онытканнар,
Бер биетик, димиләр.

К у ш ы м т а.

Чабата бит, чабата
Биергә бик ярата.
Куанычына түзалмый,
Күр, ничек тыпырдата.

К у ш ы м т а.

Әй чабата, чабата,
Күр, ничек тыпырдата!
Чабатаның тыпырдавы
Күңелемне юата.

К у ш ы м т а.

Бер йөрим әле биеп,
Яңа чабата киеп.
Чабата да бер куансын:
«Биедем әле!» – диеп.


К у ш ы м т а.

Бер йөрим әле биеп,
Яңа чабата киеп.
Ә сез яңа җыр җырлагыз,
Чабата көе, диеп.

К у ш ы м т а.

# Япь-яшь кызлар китте ут эченә…

*Р.Асиков* көе



Оныта алмам, мәңге оныта алмам
Йөрәгемнең әрнеп сызлавын
Озатканда утлы яу кырына
Назлы гөлдәй татар кызларын.

Кызлар китте җырлар җырлый-җырлый,
Ак каеннар сыгылып тыңлады.
Япь-яшь кызлар китте ут эченә,
Йөрәкләрдә калды моңнары.

Гөлләр кебек гүзәл апам китте
Гүләп торган сугыш кырына.
Каерылган пар канатлар кебек
Толымнары калды кулымда.

Киткән икән бәгърем ут эчендә
Чәчәк кебек гомерен җуярга.
Язган икән салкын толымнарын
Кайнар яшьләр белән юарга...

Гомер үтә, кайгы китә, диләр,
Ник әрнетә һаман ул моңнар?
Күз алдымнан китми пар канаттай
Сыгылып төшкән шушы толымнар...

# *Дуаным – туган авылым*

*Р.Бакиров* көе



Тып-тын гына агып яткан
Чынлы елга буенда
Дуан дигән авыл калыккан
Чал табигать куенында.

К у ш ы м т а:
Дуаным шул, Дуаным,
Сөекле туган ягым.
Җырларымда еракларга
Яңгыратыйм әле данын.

Яңгыратыйм әле данын,
Син бит минем Дуаным...
Син бит минем онытылмас
Кадерле туган ягым.

К у ш ы м т а.

Язлар килсә, Чынлы елга
Ага ярларга тулып.
Күп милләтләр яши бездә
Бер туган кебек булып.

К у ш ы м т а.

Су өсләрен нурга күмеп
Таңнар аткан чагында,
Кошлар бигрәк моңлы сайрый
Минем туган ягымда.

К у ш ы м т а.

Чынлы елга тугайларын
Күңелләрем сагына.
Бүләк булсын йөрәк җырым
Газиз туган ягыма.

К у ш ы м т а.

# *Яңа чорлар килә*

*Р.Бакиров* көе

**Moderato. Maestoso**






Халкым һаман сөю, сөю-мәхәббәтен
Җырларына салып җырлаган.
Чыңлаткан ул сазын,
Салып йөрәк назын,
Туган җирен шулай зурлаган.
Яңа чорлар килә.
Яңа җырлар белән
Каршы алыйк гасыр таңнарын.
Бар халыклар күрсен,
Яңа гасыр белсен
Күңелләрдә безнең моң барын.
Яшәгез, дусларым...

Йөрәгемдә туган, туган җиркәемә,
Үз халкыма чиксез сөю бар.
Чиксез сөю булып,
Наз-моңнарга тулып
Яңгырасын, дуслар, бу җырлар.
Авыр елларда да,
Шатлык-моңнарда да
Аерылмадык, булдык гел бергә.
Яңа чорлар килә,
Бәхет-шатлык белән
Яшәгез, дусларым, гомергә!
Яшәгез, дусларым...

# Сурелмәсен сөю ялкыны

*Р.Бакиров* көе

**Con moto**




E7 A
си - не саг(ы) - нып кө - тәм,
C♯ D F♯7 A
бер - дән - бе - рем ми - нем, ал - ты - ным.
C♯m F♯m C♯m
Күз - лә - ре - мә ка - рап ир - кә -
F♯m Hm E7
лә бер, я - рат, сүрел - мә- сен сө - ю ял - кы-
A C♯7 D C♯7 1. F♯m
ны, сү - рел - мә - сен сө - ю ял - кы - ны.
2. F♯m
Кил ин - //ны.

Көннәр нурсыз үтә,
Күңел сине көтә.
Нигә инде шулай югалдың?
Салкын күзләреңнән,
Үпкә сүзләреңнән
Күңелемдә сагыш-моң калды.

К у ш ы м т а:
Кил инде, кил, иркәм,
Мин бит сине сагынып көтәм,
Бердәнберем минем, алтыным.
Күзләремә карап
Иркәлә бер, ярат,
Сүрелмәсен сөю ялкыны.

Читтән генә күзләп,
Гаебемне эзләп,
Юкка гына җаның кыйнама.
Шикләрең хак түгел,
Шуңа әрни күңел,
Мәхәббәтем белән уйнама.

К у ш ы м т а.

Хисләрем саф, якты,
Яратуым хактыр,
Оныталмам, кая китсәң дә.
Ниләр булды сиңа,
Сөюемә нигә
Ышанмыйсың, antлар итсәм дә?..

К у ш ы м т а.

# Янма, йөрәк, сызма, күңел…

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе



Янма, йөрәк, сызма, күңел,
Өзгәләнмә, җан гынам.
Күк айкала, җир чайкала,
Сынма рухым, бул чыдам.

Халкыңны күр, хәленә кер,
Мәрхәмәт кыл, суз кулың.
Чыңласын саз, җырларың яз,
Аңа бир бар җан җылың.

Дан, димә син, мал, димә син,
Төкереп бир барына.
Тынмасын саз, җырларың яз,
Манып йөрәк канына.


Бер көн җитәр, давыл үтәр,
Нурланып ал таң туар.
Җылы язлар җаның назлар,
Ләйсән яңгырлар юар.

Ышан, күңел, ерак түгел,
Җитәр ул көн, бер җитәр.
Туган халкың саклар хакың,
Яклар исемең, үз итәр.

# *Чык син, иркәм, Идел буйларына...*

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе



Чык син иртән Идел буйларына,
Тыңла, иркәм, дулкын тавышын.
Мин сөйләрмен аңа күңелемнең
Яшерен моңын, яшерен сагышын.

Чыклар төште зәңгәр чәчәкләргә,
Язгы таңнар сызылып атканда.
Шул чыкларны күрдем күзләреңдә,
«Сөям» сүзен өзелеп әйткәндә.


Нигә качтым шул, чак көлә-көлә,
Яңгыратып Идел тугаен.
Басып калдың текә яр башында,
Ялгыз имән кебек моңаеп.

Ул минутлар инде ерак калды,
Син дә киттең ерак җирләргә.
Ә мин килдем кайнар сагышымны
Салкын дулкыннарга сөйләргә...

# Тик бирәүне көтә күңелем

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе



Син миңа, кил, дисең, сөюем бел, дисең,
Йөрәгем кушмагач, килалмыйм.
Яратам, дисәң дә, юксынам, дисәң дә,
Уңайга бер җавап биралмыйм.

Юксынма, кирәкми, борчыма йөрәкне,
Ул бит соң башканы юксына.
Аңарга илтәсе, аңарга әйтәсе
Хисләре юк бит соң, юк сиңа.

Ул инде еракта, дәшеп тә, елап та
Кайтара алмыйм бит, нишләтим?
Нишләтим теләкне, нишләтим йөрәкне,
Ансыз бит ул үксез бер ятим.

Ник икән бу йөрәк, шулкадәр дә теләп
Ярата һаман тик берәүне?
Кайда ул, ник кайтмый, таңнарым ник атмый,
Ул шулай ярата беләме?

Син һаман, кил, дисең, сөюем бел, дисең,
Йөрәк бит белергә теләми.
Бер Мәҗнүндәй булып, сагышларга тулып,
Көтә бит, көтә тик берәүне.

# Дустыма

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе

**Adagio, doloroso**



Юк, көтмә син «сөям» дигән сүзне,
Мин әйтсәм дә, дөрес сүз булмас,
Зур дуслыкның саф хисләрен таптап,
Мәхәббәтем сиңа сузылмас.

Күзләремдә шаян нурлар күрсәң,
Ут алырга аннан ашыкма.
Дөрләмәсен зәһәр ялкыннарга,
Шук җилләрдән аны ышыкла.

Ышанма син шашкын ул хисләргә,
Язгы җилдәй алар тиз үтәр.
Күңелләргә сүнмәс илһам биргән
Ихлас дуслыкларга ни җитәр!

# *Көтәр идем…*

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе

**Largo, doloroso**



Исеңдәме, язгы таңда
Күл буйларын буйладык,
Зәңгәр күлгә аккош кайткач,
Бәхетебезгә юрадык.

Адаштымы ул бәхетләр
Бормалы юлларында?
Ялгыз каршылыйм язларны
Зәңгәр күл буйларында.

Күлгә тагын аккош кайтты,
Сыкранып куйды күңел:
Пар аккошлар һаман бергә,
Без генә бергә түгел.

Сине уйлый күңелләрем,
Сызылып таңнар атса да,
Яр буйларын ямьгә күмеп,
Пар аккошлар кайтса да.

Шул ярлардан синең белән
Бер генә үтәр идем,
Аккошлардай бер кайталсаң,
Мәңге дә көтәр идем...

# *Шомыртлардан ла кара күзләре*

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе

**Adagio, dolce**



Шомыртлардан ла кара күзләре,
Алмалардан алсу йөзләре.
Нигә генә бер дә истән чыкмый
«Яратам ла»  дигән сүзләре?

Үрмә чәчләренә сәйлән үргән,
Мондый көязләрне кем күргән.
Гүзәлләрдән гүзәл бер сылуны
Ярым булыр диеп кем белгән.

Болыннарны ялгыз буйладым мин,
Чәчәкләрен аңа юлладым.
Шул чәчәкләр кебек бергә генә
Үтсәк иде гомер юлларын.


Шомыртлардан ла кара күзләре,
Алмалардан алсу йөзләре.
Нигә генә бер дә истән чыкмый
«Яратам ла» дигән сүзләре?

# Читлектә

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе






Җәйге таңда матур бер читлектә
Өзгәләнеп бер кош талпына:
«Әй, кешеләр, – ди ул, – әй, кешеләр,
Тыңлагызчы мине чак кына.
Чыгарыгыз, зинһар, тар читлектән,
Җибәрегез иркен күгемә.
Дустым калды анда, якын дустым,
Җырлар җырым калды үзенә.

Әй, кешеләр, тыңлагызчы, зинһар,
Гомеркәем минем бик кыска.
Йөрәгемдә җырлар җырым калды,
Әйтер серем калды җан дуска.
Токтынлыклар өчен түгел җаным,
Канатларым тәмам тилмерде.
Түзәр хәлкәйләрем калмады ла,
Чыгарсагыз иде сез мине...

Ирек сөйгән җаным зәңгәр күген,
Көмеш кыяларын сагына.
Кими җирдә яшәр сәгатьләрем.
Аһ!.. Очар идем оям ягына,
Аңласагыз әгәр аз гына...»
Бәргәләнеп шулай тилмерде ул,
Җим капмады, суын эчмәде.
Бер иртәне читлек ачылды, тик...
Кыймшанмады кошчык, дәшмәде...

# *Күңелдә һаман да, күңелдә...*

*(романс)*

*Х.Ибраһимов* көе



Без инде аерылдык, аерылдык,
Без инде пар ярлар түгелләр.
Нигә соң шелтәле карашың
Күңелдә һаман да, күңелдә?

Син инде еракта-еракта,
Дөнья бит ул чиксез Иделдәй.
Нигә соң «хуш!..» дигән сүзләрең
Күңелдә һаман да, күңелдә?

Мин инде башканың парымын,
Мин инде синең яр түгел лә.
Нигә соң аерылу ачысы
Күңелдә һаман да, күңелдә?

Гомерләр үтте инде, үтте инде,
Яшьлекләр мәңгелек түгел лә.
Нигә соң, нигә соң назларың
Күңелдә һаман да, күңелдә?

## *Эчтәлек*


Таңнарны да җырлар уята... *Госман Садә* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

Сүрелмәс җырым син. *Р.Еникеев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Яран гөл. *С.Чуганаев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Казаным минем, Казаным. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Китмә, сөю. *М.Шәмсетдинова* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Рәхмәт, әнкәй, сиңа. *Т.Вәлиев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Татарстан. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Син – минем язларым. *Л.Батыр-Болгари* көе . . . . . . . . . . . . . . . 18
Агыйдел агышлары. *И.Закиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Әткәем. *Л.Батыр-Болгари* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Уйнама, гармун. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Газиз туган җир генә. *И.Байтирәк* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Җырламагыз әле, әй, шул җырны. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . 28
Кермә, бәгърем, кермә төшләремә. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . 30
Сүнмәс ут яна. *Г.Максимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Пар алмагач. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Кырларыңа мәхәббәтем җырлап киләм. *Т.Вәлиев* көе . . . . . . . . . . . 36
Сипкелле кыз. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Яраттым шул, яраттым... *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Умырзая чәчәк аткан чакта. *И.Дәүләтшин* көе . . . . . . . . . . . . . . 42
Кошлар кайткан чак иде... *Г.Максимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Зәңгәр чәчәк. *Т.Вәлиев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Әткәмне сагынганда. *И.Дәүләтшин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Ак күлмәк кия иде. *И.Закиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Үпкәлисез миңа, якташларым. *Г.Максимов* көе . . . . . . . . . . . . . . 52
Их, авылым таңнары. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Үрмә гөл. *С.Чуганаев* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Кайтыр идем. *М.Морзаханов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Уйна, гармуным, йөрәгем моңын. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . 60
Сылу яр. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

Әниләр бәйрәме. *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Сайра, тальян. *И.Якупов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Яратам бит. *И.Дәүләтшин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Аккош зары. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Гөлнаракай, Гөлнара. *И.Арсланов* көе . . . . . . . . . . . . . . . 72
Әниемә. *Г.Максимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Ник югалды болай эзләрең? *Г.Әхмәтҗанова* көе . . . . . . . . . 76
Оч син, җырым! *Г.Максимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Казански күн итек. *Ф.Вафин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Кайт син, балам... *Ф.Мортазин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Ник үтми сагышларым? *А.Салихова* көе . . . . . . . . . . . . . . . 84
Туган телем. *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Далада. *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Бәхилләшми, әнкәй, ник киттең?.. *А.Салихова* көе . . . . . . . . 90
Зәңгәр күзем. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Сары төнбоек. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Кадерләрем булмады. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . 96
«Яратам» диюләрең... *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Яр буйлары – куш тирәк. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . 100
Сандугачлар серледер. *О.Усманов* көе . . . . . . . . . . . . . . . 102
Күрешер таңнар атмады. *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . . . . . . 104
Дүшәнбикәм – җан иркәм. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . 106
Сине күрсәм. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Яңа ел килә! *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Сине эзлим. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Өзгәләмә үзәгемне. *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Юксыну. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Сагышлы җыр. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Күрдем кошлар киткәнен. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . 120
Туган илкәй. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Ялгыз ана. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Яңа ел киче. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Әйдә барыйк аулак өйгә. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . 128
Әй чабата, чабата. *Т.Бадыгин* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
 Япь-яшь кызлар китте ут эченә... *Р.Асиков* көе . . . . . . . . . . 132
Дуаным – туган авылым. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . 134
Яңа чорлар килә. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136

Сүрелмәсен сөю ялкыны. *Р.Бакиров* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Янма, йөрәк, сызма, күңел... *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . 142
Чык син, иркәм, Идел буйларына... *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . 144
Тик бирәүне кәтә күңелем *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . 146
Дустыма *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Көтәр идем... *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Шомыртлардан ла кара күзләре *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . 152
Читлектә *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Күңелдә һаман да, күңелдә... *(романс). Х.Ибраһимов* көе . . . . . . . . . . . 156

Нотное издание

**Валеева** Резеда Тавгалюновна

АХ, ЛЮБОВЬ, ЛЮБОВЬ...

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Ноталы басма

**Вәлиева** Резеда Тәфкәлүн кызы

ЯРАТТЫМ ШУЛ, ЯРАТТЫМ...

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Музыкаль мөхәррире *Г.Х.Беляева*
Рәссамы *И.М.Воробьев*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 4.05.2010. Форматы 60×90 $^1/_{16}$.
Шартлы басма табагы 10,0. Тиражы 3000 д. Заказ О-518.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.